Хәмит ЛАТЫЙП

# Шигырьләрем — тәсбих төймәләре

Җырлый иде көннәр, һәм өметләр
Киләчәкле Ак таңнарда иде.
Яшьлек дәрте дулкын-дулкын кайный, —
Хисләр иле тантанада иде.

Җиде тараф җиде әкият иде,
Бөтен галәм күзгә төсле иде.
Әкият кызы көтә иде гүя
Кураенда уйнап серле көйне.

Барган юлым туры кебек иде,
Көтмәгәндә давыл-туфан кубып
Юлларыма тау-тау кайгы өйде.

Кем уйлаган ул чак афәт җиле
Өзәр диеп безнең матур көйне...

## *Көн баешы*

Ачы җилләр чал чәчемне тарый,
Борылып багам үткән елларга.
Хәтер тузанында югалтканны
Табалмыйча йөрим юллардан.

Тормыш баскан авыр иңнәремдә
Өннәр түе кебек җил йөри.
Уйлар тынгы бирми иртә-кичен,
Киләчәкләр тагын ни юрый?

Җанны кискән вакыт җилләреме
Теләкләрне күптән җимергән?
Өметләрем эшкә ашмаенча
Яфрак булып юлга сибелгән.

Офыкларда әнә көн баешы,
Соңгы кошның соңгы тавышы.
Офыкларга сеңә бара гүя
Мин яшәгән еллар сагышы.



## *Битарафлык*

Әнә бериш алар:
Исе китми
Сине тыңлап озак утырмас,
Туган телем диеп ана телен
Китаплардан эзләп укымас.

## *Ялвару*




Көннәремнең ишетелә зары,
Барып җитәсе юл бигрәк ары.
Соңгы очкын — йөрәк читлегендә,
Җылы сүзең миңа кирәк бары.

## *Идем*

Мин бу җирдә үксез бала идем:
Күңелемдә тынмас яра иде,
Хыялларым күккә бага иде,
Дөнья серен әз-мәз ача идем,
Үз-үземә бетмәс җәфа идем.

## *Өметләнү*



Суларыннан чыгып утларына кердем,
Тәкъдирләргә шулай язылгач.
Кар-бураннар күмәр әрнүләрне,
Язлар килер җанга — сагынгач.

*Бер сүзгә кушуч фикер җыйган шагыйрь генә чын. Нәкъ урынлы сүз фикергә канат куя. Күләгә дә шулай рәсемне ачып җибәрә. Кирәкле сүздән башка фикер тонык. Тәсбуяуларны бер-берсенә кушканда гына табигый. Фикер дә чын сүзләрне янәшә куйганда хакыйкатькә әйләнә.*

*Рәссам, шагыйрь Хәмит Латыйпның иҗаты шундый.*

*Төн уртасы әле таң атарга озак*
*Төннең келәсендә тора йозак*
*Йолдызсыз төн авыр уйларымны урлый*
*Урамда шомлы салкын җил дулый.*

*Бу — рәсем. Куе тәстәге рәсем. Тыныш билгеләре юк. Чөнки ул билгеләр тәэссоратның, уйның йолдызларына әйләнер иде кебек тә, фикерне тәссезләндерер шикелле. Йолдызсыз төн, карак сыман, уйларны урлый. Рәсем ачык, фикер анык. Шигырьне шул тота. Ахыр килеп, дөньяны да. Бугай.*

*Матур фикер күп сүз чытырманлыгында адашып кала. Юмарт рәсемләү зиһенне камаштыра. Хәмит Латыйп алай итми. Аның шигъри тәсбихы төгәл — туксан тугыз төймәле; сурәтләвенең тәсбих анасы да, тәсбих мулласы да күңеленең ихлас зекерендә.*

*Шигырь үзен эзләп тапканны яратмый. Ул, туфрактан борнагандай, шагыйрь күңелендә үзе чәчәк ата. Хәмит Латыйпныкылар да аның каләменә үзләре килеп куна ахрысы.*

*Ишетерсез бер сандугач сайрар*
*Таң атканда бу дөньяга киткәч*
*"Китү билгесе".*

*Аның шигырьләренә тышау салырлык түгел. Шуңа күрә алар җиңел атлый, җилдереп бара.*

*Теләгәндә аларны "төзәтеп" булыр шикелле.*

*Тик шунысы бар: иҗат әсәре фәкать укучы, тамашачы күңелендә генә тәмам камилләшә.*

*"Төзәтү" дигәннән, болайрак ул:*

*Боккалини атлы сатира, тәнкыйть остасы бер шагыйрьнең хаталарын җыйнап туплаган да Аполлонга бүләк иткән, имеш. Тегесе моны түбәнчелек белән кабул кылган, аннары тәнкыйтьче алдына җилгәрелмәгән бодай тулы бер тубал китереп куйган да кибәгеннән аерырга кушкан. Тегесе боерыкны үтәгәч, аңа кибәген бүләк иткән.*

*Игелек гаме белән язылганнан хилафлык эзләгәннең иманы кылчыклы.*

*Бактың исә, Хәмит Латыйп яшьли үксез калган икән. Аның каруы ул үз халкына ата-анасы кочагы сыйфатында сыенган да, аңа һәр сүзе, рәсеме саен "әннә", "әттә" диеп эндәшә.*

*Тормыш үтте, кемнәр юлга чыгар*
*Җиңә-җиңә язмыш бураннарын?*
*Фәрештәләр сезгә юлдаш булсын,*
*Хәерле юл телим, туганнарым*
*"Хәерле юл телим".*

*Ул — Россия Федерациясенең Рәссамнар берлеге әгъзасы, былтырдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Шәмәрдән бистәсендә яши. Рәсемнәре белән күп күргәзмәләрдә катнашкан; рәсемнәре Россиядә, Алмания, АКШ, Израиль, Төркия, Франциядә шәхси тупланмаларга сатып алынган, "Җир һәм күк" дигән китап иясе.*

*Берүк тәсбихының җебе өзелә күрмәсен иде дә, төймәләре чәчелмәсен иде.*

*Әхәт ГАФФАР.*

## *Хәерле юл телим*


Күпме гомер яшәлде лә җирдә, —
Аһ, аяусыз язмыш бураннары...
Яңалары килеп өшеткәндә,
Җылы кебек иде узганнары.

Аяусыз ла булды ул бураннар,
Килеп кайчак тынсыз калдырдылар.
Адаштырып барыр бу кырларда
Әллә инде юлдан яздырдылар.

Гомер үтте, кемнәр юлга чыгар
Җиңә-җиңә язмыш бураннарын?
Фәрештәләр сезгә юлдаш булсын,
Хәерле юл телим, туганнарым.

* * *

Гомер узган саен көннәр моңсу,
Күңелемне урый сагышы.
Бәхет табам дигән чакта гына
Бу язмышым тагын ялгышты.



Ялгышлардан
торамы соң яшәү,
Кайда аның дөрес юлы бар?
Сагышлардан чыгып арынганда
Яшәүләрдә нинди урын бар?

Гомер узды аккан сулар кебек,
Табылмастыр инде кичкәне.
Онтыйм дигән
идем кайгыларым,
Яңалары килеп өстәлде.



Барган чакта
кичеп язмышымны
Киләчәккә таба юл алып,
Өметләрем чакырганда мине
Никтер калдым тагын югалып.

Аваз салып анда үткәннәрем,
Янган өмет булып калгандыр.
Бара-бара үз сукмагым буйлап,
Ялгыз җаным тагын талгандыр...



## *Кем уйлаган?*

Мин еракта юлда идем ул чак,—
Тормыш даласында
ялгыз илче.
Тормыш миңа шундый кызык иде,
Күк каты да ул чак җиде иде.